**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге составына керүче Иске Урыссу торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**27.11.2020 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 27 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Иске Урыссу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш 2021 елда үзара салым кертүгә 1500 сум күләмендә түләргә һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга ризамы:

- Октябрь урамы, Елга урамы, 1 Май урамы буенча Иске Урыссу торак пункты юлларын норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, асфальт салу, ремонт, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Иске Урыссу бистәсендә Хәтер скверын төзү (проект төзү, проект төзү буенча хезмәтләр, төзелеш материаллары һәм җиһазлары сатып алу, сквер территориясенә нигез салу, мемориал сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

Иске Урыссу торак пункты юлларын кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү)» соравы буенча.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 575 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 293 кеше катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында 278 катнашучы «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 15 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар чыгарды:

1. Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Иске Урыссу торак пунктында халык җыены узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. “Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Иске Урыссу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш 2021 елда үзара салым кертүгә 1500 сум күләмендә түләргә һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга ризамы:

- Октябрь урамы, Елга урамы, 1 Май урамы буенча Иске Урыссу торак пункты юлларын норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, асфальт салу, ремонт, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Иске Урыссу бистәсендә Хәтер скверын төзү (проект төзү, проект төзү буенча хезмәтләр, төзелеш материаллары һәм җиһазлары сатып алу, сквер территориясенә нигез салу, мемориал сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

Иске Урыссу торак пункты юлларын кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү)» буенча сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Урыссу авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен юлларга.

Җыенда рәислек итүче,
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Әминова